ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.09.2021 М ө с л и м № 424

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә җир эшләрен җитештерүгә ордерлар (рөхсәтләр) бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 25 февралендәге 71 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә җир эшләрен җитештерүне тәртипкә салу һәм төзекләндерүне яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә җир эшләрен җитештерүгә ордерлар (рөхсәтләр) бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 25 февралендәге 71 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктыннан 11 абзацны төшереп калдырырга;

1.2. 2.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле «г» пунктчасы белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына, Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү срогы җиткән салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә сората (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш)».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**4.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**